СОВЕТ СУНЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Яруллина, д.7а, с. Малая Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422173

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яруллин ур., 7а йорт, Кече Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422173

тел.(факс): (85563) 3-07-03; e-mail: Sun.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**КАРАР**

№ 1-39 24.09.2024 ел

## Физик затлар мөлкәтенә салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында " 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының "Сон авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Сон авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Сон авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә мәҗбүри түләүгә салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә:

2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

2.1 0,1% нисбәттә:

- гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән әлеге пунктның 2.4 пунктчсында күрсәтелгән салым салу объектларында урнашканнары,.;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган хуҗалык корылмалары;

2.2 0,2 % нисбәттә:

- квартиралар, квартира өлешләренә;

2.3 0,3 % нисбәттә:

- торак йортлар, торак йортларның өлешләренә;
- төзелеп бетмәгән объектларның проектлана торган билгеләнеше торак йорт булган очракта;
- составына торак 1 йорт булса да кергән бердәм күчемсез комплекслар;

2.4. Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата 2 %нисбәттә;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына;

- һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына;

2.5. Салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнә торган салым салу объектлары исемлеген административ - эшлекле билгеләнештәге объектлар, сәүдә үзәкләре һәм алардагы 1000 кв. м дан артык мәйданлы биналар белән киңәйтү өлешендә 1,2% нисбәттә.

2.6. Башка салым салу объектларына карата 0,5 %.

3. Ташлама ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йортта фатир милекчеләренә исәпләнгән салым суммасын әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метрының кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага киметү рәвешендә бирелә..

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташлама суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә..

Фатир уртак милектә булган очракта, ташлама суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Бу чакта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташлама суммасы исәпләнгән салым суммасыннан аны исәпкә алмыйча гына арта алмый.

4. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә:

4.1. 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарны;

- әлеге пунктның 1 бүлегендә күрсәтелгән гражданнарның балигъ булмаган балаларын.

4.2. Салым ташламасы салым түләүче милкендәге һәм салым түләүче тарафыннан эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле салым суммасы билгеләнгәндә салым ташламасы салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә салым түләүче сайлаган һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатир, фатирның бер өлеше яисә бүлмә;
2) торак йорт яисә торак йортның бер өлеше;
3) Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясындагы 1 пунктының 14 пунктчасында күрсәтелгән бина яисә корылма;
4) Россия Федерациясе Салым кодексының 1 пунктының 15 пунктчасында күрсәтелгән хуҗалык төзелеше яисә корылма;
5) гараж яисә машина урыны.

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларына карата салым ташламасы

бирелми, мондый салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары моңа керми.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына үз теләкләре буенча салым ташламасы бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документлар тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасы бирелә торган сайланган салым салу объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым органына күрсәтелгән объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган салым чоры булган елның 1 ноябренә кадәр үз теләге белән тапшырыла.

Салым органына сайланган салым салу объекты турында хәбәрнамә тапшырган салым түләүче, салым чоры булган елның 1 ноябреннән соң, күрсәтелгән салым чорында салым ташламасы бирелә торган салым салу объектына үзгәрешләр кертеп, төгәлләштерелгән хәбәрнамә тапшырырга хокуклы түгел.

Салым ташламасына хокуклы салым түләүче сайланган салым салу объекты турында хәбәрнамә тапшырмаганда, салым ташламасы һәр төрдәге салым салуның максималь исәпләнгән суммасы булган бер объектына карата бирелә.

4.3. Хәрби хәрәкәтләр ветераннары һәм инвалидлары-хәрби хезмәттән азат ителгән махсус хәрби операциядә катнашучылар.

4.4. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында»2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары, махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр, салым салу объекты милекчеләре.

4 пунктның 4.3. һәм 4.4. подпунктлары буенча салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә: фатир, фатир өлеше, бүлмәләр, торак йорт яисә торак йорт өлеше.

Салым ташламасы салым түләүчеләргә салым түләүче милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган бер салым объектына карата салым түләүче тарафыннан түләнергә тиешле күләмдә бирелә.

5. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Сон авыл җирлеге Советы карарларының үз көчен югалтуын танырга.:

- 15.10.2015 ел, №1-2 «Мөлкәткә салым турында»;
- 05.06.2018 ел, №5-32 " Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге Советының "Физик затлар мөлкәтенә салым турында"2015 елның 15 октябрендәге 1-2 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында";
- 20.05.2019 ел, №1-42 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында "Сон авыл җирлеге Советының 04.06.2015 ел, N 3-45 карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»;
- 2023 елның 20 февралендәге 1-22 номерлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге Советының "Физик затлар

мөлкәтенә салым турында"2015 елның 15 октябрендәге 1-2 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында";

- 2023 елның 15 ноябрендәге 3-30 номерлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге Советының "Физик затлар мөлкәтенә салым турында"2015 елның 15 октябрендәге 1-2 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында";

- 2023 елның 27 декабрендәге 3-32 номерлы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Сон авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 ноябрендәге 3-30 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында".

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча «Норматив документлар»бүлегендә урнаштырырга.

7. Әлеге карарның гамәли көче 2024 елның 1 гыйнварыннан физик затлар мөлкәтенә салым исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, әлеге карарның 2.5 пунктыннан тыш, ул 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Сон авыл җирлеге башлыгы М.Ф.Сәләховка йөкләргә.

Сон авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы / М.Ф.Сәләхов /